| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.01.2026 г. Агрыз № 6-5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021 елның 29 июнендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иҗтимагый советы турында"гы 10-1нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, "Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында"гы 2022 елның 31 декабрендә кабул ителгән 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021елның 29 июнендә кабул ителгән 10-1 номерлы «Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районының Иҗтимагый советы турында»гы карарына (алга таба – Карар ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-1.2. пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы – Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

-Карарның 7.2. пунктының 5.1. пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында ) Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л. Ф. Нургаянов